БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
13 декабрь 2024 ел

**КАРАР**
№ 296

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган, муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару хокукында яки оператив идарә хокукында беркетелгән милекне арендага тапшыруны килештерү Тәртибен раслау турында**

«Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясының $3^5$ өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары белән расланган муниципаль яки дәүләт мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль яки дәүләт милкенә конкурс яки аукционнар үткәрмичә генә аренда шартнамәләрен төзү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган, муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яисә оператив идарә хокукында беркетелгән милекне арендага тапшыруны килештерү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И.М.Фәтхетдиновка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2024 елның 13 декабрендәге
296 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган, муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару хокукында йә оператив идарә хокукында беркетелгән милекне арендага тапшыруны килештерү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мәдәният оешмасы(алга таба – муниципаль мәдәният оешмасы) тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәтендә булган, хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль милекне гамәлгә куючы һәм аның милекчесе белән конкурслар яки аукционнар уздырмыйча гына арендага тапшыруны килештерү процедурасын билгели.

2. Муниципаль мәдәният оешмасы «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясындагы $3^5$ өлеше нигезендә аренда шартнамәсе төзү кирәклеге турында гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге «Хуҗалык алып бару хокукында дәүләт яисә муниципаль оешмаларга беркетелгән дәүләт яисә муниципаль милеккә карата аренда шартнамәләрен конкурслар яисә аукционнар уздырмыйча гына бәяләмә төзү яисә оператив идарә итү кагыйдәләрен раслау турында» 1529 номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район мөлкәтенең милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен, шулай ук гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет), мөрәҗәгать итүчегә мөлкәтне арендага бирүне килештерү турындагы мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) җибәрә.

3. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) фаразланган арендаторның исеме, аның урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы һәм контакт телефон номеры;

2) арендага тапшырырга тәкъдим ителә торган хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт турында белешмәләр;

3) хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруның аны нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итүен нигезләү;

4) аренда шартнамәсен төзү тәкъдим ителә торган вакыт;

5) мөлкәтне арендага бирү өчен конкурс яисә аукцион уздырмыйча гына күздә тотыла торган арендаторны сайлауның хокукый нигезләмәсе:

а) арендаторның мөлкәткә ихтыяҗы, мөлкәттән файдалануның күздә тотылган максатлары;

б) муниципаль мәдәният оешмасына килүчеләргә һәм хезмәткәрләргә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган продукциянең һәм товарларның ассортименты турында мәгълүмат - җәмәгать туклануын оештыру өчен;

в) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция ассортименты турында мәгълүмат - ваклап сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен.

4. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар теркәлә:

1) мөлкәтне арендалау шартнамәсенең проекты;

2) Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең бәясен бәяләү турында хисап (тапшыру датасына 90 көннән дә артык булмаган вакыт аралыгы белән);

3) күздә тотылган арендаторның гариза күчермәсе (җәмәгать туклануы оешмалары, сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция белән ваклап сатуны гамәлгә ашыручы юридик зат яисә шәхси эшкуар);

4) шәхесне таныклый торган документның күчермәсе һәм индивидуаль эшкуарлар өчен Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (30 көннән артмаган срок белән) - шәхси эшкуарлар өчен;

5) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (30 көннән артмаган срок белән) - юридик затлар өчен.

5. Муниципаль мәдәният оешмасына милекнең бер төрен (төрләрен) арендалауга карата ике һәм аннан күбрәк гариза бирүчеләрнең заявкалары кергән очракта, мөрәҗәгать гариза кергән датадан чыгып чират тәртибендә җибәрелә.

6. Башкарма комитет мөрәҗәгатьне һәм аңа кушып бирелгән барлык документларны алар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) милекне арендага тапшыруны килештерергә;

2) милекне арендага тапшыруны килештерүдән баш тартырга.

7. Милекне арендага тапшыруны килештерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) милекне арендага тапшыру муниципаль мәдәният оешмасы эшчәнлеген нәтиҗәлерәк оештыруга ярдәм итмәячәк;

2) милекне арендага тапшыру максатлары муниципаль мәдәният оешмасының уставында каралган эшчәнлек төрләренә туры килми;

3) милекне арендага тапшыру чират тәртибендә элек кергән гаризаны карау нәтиҗәләре буенча килештерелгән.

8. Кабул ителгән карар Балтач район башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хокукый акт формасында рәсмиләштерелә һәм кабул ителгән көненнән алып 7 көн эчендә муниципаль мәдәният оешмасы тарафыннан җибәрелә.

9. Милекне арендага тапшыруны килештерүдән баш тарту турындагы карар нигезләнгән кире кагу сәбәпләрен үз эченә алырга тиеш.

Милекне арендага тапшырудан баш тарту турында карар кабул иткәндә, аңа теркәлә торган документлар мондый карар кабул ителгән көннән алып 7 көн эчендә муниципаль мәдәният оешмасына кире кайтарыла.

10. Милекне арендага тапшыруны килештерү турында кабул ителгән карар муниципаль мәдәният оешмасы тарафыннан конкурс яисә аукционнар уздырмыйча милекне арендалау шартнамәсен төзү өчен нигез була.

11. Муниципаль мәдәният оешмасы аренда шартнамәсе төзелгән көннән соң 10 көн эчендә аренда шартнамәсе төзү турында башкарма комитетка язма рәвештә хәбәр итә (арендага тапшырылган милек исемлеге һәм аны арендага бирү срогы күрсәтелгән кушымта белән).